РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» 12 2018 г. №1026

2019 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучылар туклануын оештыру турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга айлык акчалата һәм түләүләрнең башка төрләре турында» 2018 елның 10 сентябрендәге 767 номерлы карары нигезендә һәм Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм укучыларны туклandыруны оештыру максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 1 гыйнварыннан расларга:

- Урыссу ш. т. б. гомуми белем бирү учреждениеләренең бер укучысына көненә 42 сум 40 тиен күләмендә туклану бәясен, шул исәптән:
- уку чорында бер укучыга бер көнгә 7 сум 40 тиен күләмендә субсидияне,
- уку чорында бер укучыга көнгә 35 сум 00 тиен күләмендә ата-ана взносы суммасын;
- авыл гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алучы бер укучыга көнгә 39 сум 40 тиен күләмендә туклану бәясен, шул исәптән:
- уку чорында бер укучыга бер көнгә 7 сум 40 тиен күләмендә субсидияне;
- уку чорында бер укучыга көнгә 32 сум 00 тиен күләмендә ата-ана взносы суммасын.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә социаль якланмаган гаиләләрдән

укучыларны тукландыруны оештыру тәртибе турында Нигезләмәне расларга (Кушымта).

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы 2019 елга муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыру чыгымнарын «Мәгариф» тармагы буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджетында әлеге максатларга каралган акчалар чикләрендә финанслауны тәэмин итәргә тиеш.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

ТР Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе С. П. Самонина

Г. М. Гыйлаҗева

2-71-00

Кушымта
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
______________2019 № ________

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларның ташламалы туклануын оештыру турында
Нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны кайнар аш белән тәэмин итүне оештыру максатларында, укучыларның түбәндәге категориясе өчен кертелде:

18 яшькә кадәрге 4 һәм аннан да күбрәк балалары булган гаиләләргә. Гомуми белем бирү учреждениеләрендә балалары өч һәм аннан да күбрәк булган гаилә категориясендәге укучылар ташламалы туклану белән тәэмин ителә.

Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә туклану өчен ата-аналар кертемнәрен түләүдән азат итү юлы белән әлеге категориягә адреслы социаль ярдәм 2019 елга гомуми белем бирү учреждениеләренең бюджет ассигнованиеләре кысаларында гамәлгә ашырыла.

2. Туклану җирле бюджет акчасына шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе гомуми белем бирү учреждениеләренең 1 укучысына - көненә 42 сум 40 тиен һәм авыл гомуми белем бирү учреждениеләренең 1 укучысына көненә 39 сум 40 тиен күләмендә оештырыла.

3. Әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында санап үтелгән укучыларны кайнар аш белән тәэмин итүне оештыру өчен, составына директор, педагогик коллектив арасыннан укучыларны туклandыруны оештыру өчен җаваплы кеше һәм ата-аналар комитеты вәкилләре кергән комиссияләр төзелә. Комиссия әгъзаларының гомуми саны кимендә өч кеше булырга тиеш.

Уку елы башында һәм алга таба да комиссия тәкъдим ителгән гаризаларны карый һәм укучыларны өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗлар исемлегенә кертү турында карар кабул итә;

4. Сыйныф җитәкчеләре:

- әти-әниләрдән яки аларны алыштыручы затлардан бушлай туклану алуга гаризалар, раслаучы документлар (белешмәләр) кабул итә: гаилә хәле, гомуми белем бирү учреждениесендә белем алулары турында;

- гаризалар алынганнан соң өч көн эчендә комиссия каравына җибәрелә;

- категорияләр буенча сыйныфта укучыларның туклануын исәпкә алып баралар;

- укучылар һәм ата-аналар арасында мәктәп укучыларының тулы кыйммәтле тукланыуы зарурлыгы турында аңлату эшләре алып баралар;

- сыйныф укучыларының барысының да ашханәдә йөрүен тикшереп тора;

- сыйныф укучыларының ашханәдә тукланулары вакытында анда торалар.

5. Ата-аналар яки аларны алыштыручы затлар тапшырылган документларының дөреслеге өчен җаваплы була.

6. Гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләре:

6.1. Укучыларны категория буенча бушлай туклану белән тәэмин итүгә боерыклар чыгара.

6.2. “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе категорияләре буенча укучылар исемлеген тәкъдим итә.

7. “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ укучыларны туклaндыруны оештыру, ашарга әзерләү технологиясен үтәү, азык-төлек блокларында санитар нормаларны үтәү мәсьәләләренә кураторлык итә.